**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Кара-Елга торак пунктында гражданнар җыены карары**

23.11.2022 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең Кара-Елга торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан ,кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең Кара Елга авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2023 елда узара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбендәге җирле мәсьеләләрне хәл итү өчен тотарга:

- Кара Елга авылы чишмәсен төзекләндерү.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Сәвәләй авыл җирлеге башлыгы И.А.Галимов